| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

«22» сентябрь, 2025 Олы Кайбыч ав. № 2

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгын, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы Рәисен сайлау турында

«Гавами хакимият бердәм системасында җирле үзидарәне оештыру гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставының 38 статьясы, яшерен тавыш бирү нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе утырышының 2 нче беркетмәсе нигезендә, Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы Рәисе итеп Рәхмәтуллин Альберт Илгизәр улын сайларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырырга.

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы
Советы утырышында рәислек итүче,
Колаңгы авыл җирлеге
депутаты Р.Р. Хәялиев